Без-
дөнья
балалары

Мы - дети мира

Җырлар
Песни

Казан
"Рухият" нәшрияты
2001

ББК 85.9 (2 Рос. Тат.)

Төзүчесе:
Ренат Хәкимов

Составитель:
Ренат Хакимов

Музыка редакторы:
Мәсгудә Шәмсетдинова

Музыкальный редактор:
Масгуда Шамсутдинова

Без – дөнья балалары = Мы – дети мира. - Казан: Рухият, 2001. - 68 бит.

Бу җыентыкта нефть төбәге композиторларының балалар өчен язылган җырлары тупланган.

В этом сборнике собраны детские песни композиторов нефтяного региона.

“Рухият” нәшрияты. Тел.: (8432) 435372, (88553) 25540. Лицензия №190

ISBN 5-89706-026-6

© Издательство “Рухият”, 2001

СҮЗ БАШЫ

Ел саен Әлмәт шәһәрендә "Сандугач сайрар илем" дип исемләнгән бик матур җыр фестивале уздырыла. Балалар иҗатына багышланган бу ямьле бәйрәмдә сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат тәмен татып караган ике меңнән артык бала катнаша. Хор коллективлары, вокаль ансамбльләр һәм ялгыз башкаручылар көч сынаша торган номинация аеруча кызыксыну уята. Иҗатчы балалар белән шөгыльләнүче укытучылар һәм остазлар бала-чаганың күңел ихтыяҗына тәңгәл, шул ук вакытта конкурста катнашучыларның профессиональ башкару осталыгын яхшырта торган репертуар юклыгын тоя.

Әлеге җыентык бу мәсьәләне өлешчә җиңеләйтер, балалар өчен яраклы матур да, эчтәлекле дә музыка сайлап алырга ярдәм итәр.

"Без – дөнья балалары" дигән җыентык – соңгы елларда Әлмәт шәһәрендә иҗат ителгән вокаль әсәрләрне бер китапта тупларга омтылыш. Әсәрләрнең авторлары – төрле һөнәр ияләре. Тик аларны бер нәрсә – балаларга һәм балалар иҗатына мәхәббәт берләштерә. Җырларны сайлаганда аларның ни дәрәҗәдә таралган булуына игътибар ителде. Җыентыктагы җырлар һәм жанр, һәм стиль ягыннан аерыла. Берсе халык иҗатына якын торса, икенчесе эстрада музыкасына аһәңдәш, өченчесендә һәр ике юнәлеш тигез үрелеп бара.

Җыр авторлары "Без – дөнья балалары" дигән җыентыкны дөньяга чыгару мөмкинлеге биргән өчен "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең "Рухият" рухи яңарыш фондына зур рәхмәтле.

ЗАРИПОВА ГӨЛНАЗ ЗАКУАН кызы

1980 елда Азнакайда туган. Музыка мәктәбен тәмамлаганнан соң Әлмәт музыка училищесында укыган. 1999 елдан Казан консерваториясенең теория бүлегендә укый. Ул – байтак җырлар авторы. Аларның күбесе балалар өчен. Аның җырлары моңлы, аңлаешлы. Музыка мәктәпләренең хор коллективлары ул җырларны еш җырлый, алар Татарстан радиосы аша да яңгырый.

ГЫЙЛЬФАНОВА ЭЛЬМИРА ХАТЫЙП кызы

1966 елда Әлмәттә туган. Музыка мәктәбендә, аннары Лениногорск музыка-педагогия училищесында музыка дәресләре алып барган. 1997 елдан батырма электр җиһазларына хезмәт күрсәтү үзәк базасында инженер булып эшли.

Аның иллеләп җыры бар. Җырларның күбесе Әлмәт шагыйрьләре – Р.Вәлиуллин, К.Булатова, Ә.Фәтхи, Г.Афзал, М.Борһанов сүзләренә язылган.

МАКСЮТИНА НАТАЛИЯ ИВАНОВНА

1971 елда Әлмәттә туган. 1990 елда Әлмәт музыка училищесын тәмамлаган. Аннары Казан педагогия институтында белем алган. Хәзер балалар музыка мәктәбендә укыта. Музыка мәктәбе репертуары өчен җырлар язу белән бергә фортепиано өчен әсәрләр дә иҗат итә.

ТАҺИРОВА ЛИЛИЯ РАМИЛ кызы

1973 елда туган. Әлмәт музыка училищесын тәмамлаганнан соң Казан консерваториясенең композиторлар хәзерли торган бүлегенә укырга керә. Төрле жанрларда актив яза. Иҗатында халыкның борынгы көйләрен заманча аһәңнәр белән яңартырга омтыла.

ХӘКИМОВ РЕНАТ ФАИЛ улы

1961 елда Азнакайда туган. Әлмәт музыка училищесында фортепиано классында белем алган. Казан дәүләт консерваториясенең фортепиано һәм композиция бүлекләрен тәмамлаган. 1997 елдан Татарстан Композиторлар берлеге әгъзасы. "Европа-Азия" халыкара музыка фестивальләрендә катнашкан. Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премия лауреаты. Әлмәт музыка училищесында укыта.

ГАЛИЕВ ФӘРИТ РӨСТӘМ улы

1947 елда туган. Әлмәт музыка училищесын баян классы буенча тәмамлаган. Аннары Казан дәүләт консерваториясенең халык уен кораллары факультетында укыган. Хәзер Әлмәт музыка училищесында укыта. Ул язган әсәрләр арасында баян, скрипка, фортепиано өчен пьесалар, җырлар бар.

ПРЕДИСЛОВИЕ

Ежегодно в городе Альметьевске проходит замечательный праздник детского творчества – региональный фестиваль "Страна поющего соловья". Каждый раз он собирает более двух тысяч творчески одаренных детей. Одна из самых популярных номинаций фестиваля – вокальное творчество, где состязаются хоровые коллективы, вокальные ансамбли и солисты. Проблемой для их руководителей и педагогов остается подбор современного репертуара, который соответствовал бы возрасту и исполнительскому уровню юных конкурсантов. Данный сборник как раз и призван помочь им, предложить яркую и разнообразную по содержанию музыку.

Сборник "Без – дөнья балалары" ("Мы – дети мира") включает вокальные сочинения для детей, написанные в последние годы профессиональными и самодеятельными композиторами Альметьевска. Большинство из этих песен уже завоевали популярность, их с удовольствием включают в свой репертуар детские коллективы и отдельные исполнители. Песни данного сборника различны по жанру и стилистике: одни ближе к народной музыке, другие – к эстрадной, а в третьих органично сочетаются оба эти направления.

Авторы песен выражают огромную благодарность сотрудникам Фонда духовного возрождения "Рухият" АО "Татнефть" за возможность издания сборника "Без – дөнья балалары".

ЗАРИПОВА ГУЛЬНАЗ ЗАКУАНОВНА

Родилась в 1980 году в Азнакаеве. После окончания музыкальной школы поступает в Альметьевское музыкальное училище. С 1999 года обучается в Казанской государственной консерватории. Ею написано большое количество песен, в том числе для детей. Для песен характерны мелодичность, доступность; они неоднократно исполнялись хоровыми коллективами музыкальных школ, были записаны на радио РТ.

ГИЛЬФАНОВА ЭЛЬМИРА ХАТИПОВНА

Родилась в 1966 году в Альметьевске. Обучалась в музыкальной школе и в 1982 году поступила в Лениногорское педагогическое училище. После окончания училища работала музыкальным работником в детском садике. С 1997 года работает инженером в ЦБПО ЭПУ.

Написала свыше 50 песен. Большая их часть – на стихи поэтов города Альметьевска: Р.Валиуллина, К.Булатовой, А.Фатхи, Г.Афзала, М.Бурганова.

МАКСЮТИНА НАТАЛИЯ ИВАНОВНА

Родилась в 1971 году в Альметьевске. В 1990 году закончила Альметьевское музыкальное училище по классу фортепиано. В 1991-1996 годы училась в Казанском педагогическом институте. Работает преподавателем детской музыкальной школы. Помимо песен пишет фортепианную музыку.

ТАГИРОВА ЛИЛИЯ РАМИЛЬЕВНА

Родилась в 1973 году. После окончания Альметьевского музыкального училища по классу фортепиано поступает в Казанскую государственную консерваторию на теоретико-композиторское отделение. Активно работает в различных жанрах. В своем творчестве органично соединяет элементы древних пластов народной музыки с современными средствами выразительности. Для песенного аккомпанемента характерна развитая фортепианная фактура; ощущается увлеченность автора джазом.

ХАКИМОВ РЕНАТ ФАИЛЕВИЧ

Родился в 1961 году в Азнакаеве. В 1979 году закончил Альметьевское музыкальное училище по классу фортепиано. Казанскую государственную консерваторию закончил по двум специальностям – фортепиано (1989 г.), композиция (1996 г.). Член Союза композиторов РТ с 1997 года. Участник пленумов СК РТ, международных фестивалей "Европа-Азия" (1998 г., 2000 г.). Лауреат премии имени Рафаэля Тухватуллина (1999 г.). Работает преподавателем в Альметьевском музыкальном училище.

ГАЛЕЕВ ФАРИТ РУСТАМОВИЧ

Родился в 1947 году. Альметьевское музыкальное училище закончил в 1968 году по классу баяна. В 1968-1973 годы учился в Казанской государственной консерватории на факультете народных инструментов (класс баяна). После окончания работает преподавателем в Альметьевском музыкальном училище. Среди его произведений – пьесы для баяна, скрипки, фортепиано, песни.

Без — дөнья балалары

Гөлназ Зарипова музыкасы
Роберт Миңнуллин сүзләре

Animato





Дәшәбез сезгә, өлкәннәр,
Без — дөнья балалары;
Балаларның сарылары,
Аклары, каралары.

Кушымта:

Кояшлы булырга тиеш
Безнең һәрбер иртәбез.
Без сездән тынычлык белән
Бәхет таләп итәбез.

Өзмәгез сез чәчәкләрне,
Безсез нишләр киләчәк?
Без булмасак, җиребез бит
Суыначак, кибәчәк.

Кушымта.

Киләчәкнең зур сурәтен
Безнең ясыйсы килә.
Җырдан гөрләвен телибез
Әйләнә тирәбезнең.

Кушымта.

Әлли-бәлли бәү

Гөлназ Зарипова музыкасы
Басыйр Рафиков сүзләре

Con moto







Әлли-бәлли бәү тирбәтә
Бишегеңне Җир шары.
Йокла син, күз нурым,
Төн сүндергән утларын.

Әлли-бәлли бәү, нәнием,
Йоклаган елга-күлләр,
Йоклаган чәчәкләр,
Шаярып йөргән җилләр.

Әлли-бәлли бәү, йолдызым,
Өметем бит син минем.
Йокла син, күз нурым,
Ак юлың алда синең.

Энемнең туган көне

Гөлназ Зарипова музыкасы
Азат Садриев сүзләре

Allegretto





Энем сыза гармунда,
Ә мин сузам курайда.
Уйныйбыз “Туган телне” —
Энемнең туган көне.
Тыпырдыйлар башмаклар,
Калмый бугай такмаклар.
Өй эче сәхнә кебек,
Ничек торырга түзеп.

Әпипәгә борылдык,
Әби төште биергә.
Читек-кәвеш мазарын
Онытса да кияргә.
Әй, шәп баса әбием,
Тотса да арттан билен.
Бик тырышсам да, алай
Мин булдыралмас идем.

Энем сыза гармунда,
Ә мин сузам курайда.
Уйныйбыз “Туган телне”—
Энемнең туган көне.
Өй эче сәхнә кебек,
Әниләр тора көлеп.
Бүген бит бәйрәм көне —
Энемнең туган көне.

Минем җырлыйсым килә

Гөлназ Зарипова музыкасы
Лена Шагыйрьҗан сүзләре

Allegretto



Гөлнең үсәсе килә,
Суның агасы килә,
Җилнең исәсе килә,
Минем җырлыйсым килә.

Кушымта:

Кояш күктә нур сибә,
Минем җырлыйсым килә:
Ил-лә, лил-лә, ил-ләл-лә —
Минем җырлыйсым килә.

Сандугачлы тал-тирәк,
Җырламаган бик сирәк,
Бергә-бергә җырларга
Безгә яңа җыр кирәк.

Кушымта.

Тизрәк үсәсем килә,
Илләр гизәсем килә.
Җырлый-җырлый илемә
Хезмәт итәсем килә.

Кушымта.

Балалар тавышы

Гөлназ Зарипова музыкасы
Хәй Вахит сүзләре

Vigoroso



Оя ясадык үзебез,
Иренмәдек, тырыштык.
Ак күгәрченнәр үстердек
Теләп җиргә тынычлык.

Кушымта:

Канат кагып ил күгендә
Әнә, ничек очалар.
Ак күңелле һәр кешегә
Сөекле кош ич алар.

Алга карап, биеккәрәк
Очсын кошларыбыз.
Ерак илләргә җитсеннәр
Тынычлык дусларыбыз.

Кушымта.

Һәр таң бәхет бирә безгә,
Бәхет йорты – илебез,
Бәхет йорты илебезгә
Без тынычлык телибез.

Кушымта.

Син кайгырма, әнкәй!

Гөлназ Зарипова музыкасы
Гөлзада Әхтәмова сүзләре



Канатланып сары күбәләктәй,
Ашкынам мин яшел болынга.
Мин югалмам чәчәк дөньясында,
Син кайгырма, әнкәй, кайгырма.

Сыенам мин синең кочагыңа
Күкрәгеңнән көчләр алырга.
Синең назың шифа әрнүләргә,
Син кайгырма, әнкәй, кайгырма.

Туган йортны бер көн онытыр да
Кире кайтмас, диеп уйлама.
Син бит минем иң кадерле кешем,
Син кайгырма, әнкәй, кайгырма.

Күрәчәкне, киләчәкне уйлап
Вакытыннан элек ачынма.
Бәлки җирдә иң бәхетле миндер,
Син кайгырма, әнкәй, кайгырма.

Койрык

Гөлназ Зарипова музыкасы
Гөлзада Әхтәмова сүзләре

Allegretto



Нәни песи баласы
Койрыгы белән уйный.
Әйләнә, тота алмый,
Уйнап һич кенә туймый.

Койрык исә селкенә,
Уңга-сулга борыла.
Кирәкми бер уенчык
Йомшак койрык барында.

Әй, койрыгын куа ул,
Тотса, бер тешләр иде.
Үз койрыгы икәнен
Белсә, тик нишләр иде?

Кар кызы

Гөлназ Зарипова музыкасы
Гөлназ Гарипова сүзләре



Яңа елның йолдызы —
Кар кызы ул, Кар кызы.
Энҗе-мәрҗән, асылташ —
Кар кызы ул, Кар кызы.

Кушымта:

Ул кызларның асылы,
Кар кызы, әй, Кар кызы!
Нурлы бәйрәм — Яңа елда
Кояш булып балкыды Кар кызы.

Кичәбезгә тулган ай да
Нур сирпеде, нур сызды.
Күкләрдә юк йолдыз бит син,
Кар бөртеге — Кар кызы.

Кушымта:

Йолдызлар бит бар да якты,
Юк йолдызның нурсызы.
Иң нурлысы, иң яктысы,
Иң гүзәле — Кар кызы!

Инеш

Гөлназ Зарипова музыкасы
Клара Булатова сүзләре



Ярларына яшел үлән үскән,
Инеш суы ага тын гына.
Тарсынмый ул үзенең барыр юлын,
Салмак кына уза, моң гына.

Кушымта:

Инеш суы ага сабыр гына,
Читләрендә үскән камышлар.
Бер карасаң, җырлар җырлый кебек,
Бер карасаң, гүя сагыш бар.

Диңгезләрне төштә күрәдер ул,
Иртәләрен шуны уйлыйдыр.
Бәлки кызыгадыр төштә күреп
Ярларыннан ташкан суларны.

Кушымта.

Уйна, дускай, гармуныңны

Гөлназ Зарипова музыкасы
Шәриф Биккол сүзләре



Уйна, дускай, гармуныңны,
Моңы агылсын әле.
Күңелемнең кылларына
Чиртсен, кагылсын әле.

Кушымта:

Уйна, уйна – тартып уйна:
Бер генә җырлыйм әле;
Уйна, уйна – тартып уйна:
Күңлем хушлансын әле.

Уйна, дускай, гармуныңны,
Бер шатлык алыйм әле.
Сагындырган яшьлегемә
Бер кайтып урыйм әле.

Кушымта.

Уйна, дускай, гармуныңны,
Моңы агылсын әле.
Аксын сагыш буалары —
Ярларын ерыйм әле.

Кушымта.

Өебезнең кояшы

Эльмира Гыйльфанова музыкасы
Фирая Зыятдинова сүзләре



Минем әби япь-яшь әле,
Минем әби чип-чибәр.
Әбине күргән кешеләр:
“Кызлар кебек син”, — диләр.

Әбием гел көлеп тора,
Йөзе нур сибеп тора.
Көне буе ничек армый —
Куллары биеп тора.

Минем әби шундый жылы —
Гел сыенасы килә.
Яннарында песи кебек
Сырпаланасы килә.

Балачагым

Эльмира Гыйльфанова музыкасы
Энҗе Афзалова сүзләре



Балачагым — нурлы ил,
Балачагым — җырлы ил.
Бергә, бергә уйныйк, әйдә,
Син дә безнең янга кил.

Балачакның бакчасында
Көлке уеннар гына.
Бергә-бергә уйныйк, әйдә,
Бергә күңелле була.

Биибез дә, җырлыйбыз да,
Күңелләр ташып тора.
Балачак ул — иң ямьле чак,
Үзенә тартып тора.

Тургай

Эльмира Гыйльфанова музыкасы
Айрат Мурзыев сүзләре



Зәңгәр күктә сайрый-сайрый
Бер нәни кош талпына.
Йөрәк җырын багышлый ул
Тырыш хезмәт халкына.

И мактыйсы килә аның
Игенченең хезмәтен.
Баш очында гына сайрап
Әйтә аңа рәхмәтен.

Кар бөртекләре

Эльмира Гыйльфанова музыкасы
Мизхәт Хәбибуллин сүзләре



Асыл ташлар күк
Кар бөртекләре.
Җем-җем киләләр,
Исең китмәле.

Өй түбәләре,
Койма башлары,
Әйтерсең елтыр
Йөзек кашлары.

Югала, сүнә
Мең-мең асылташ,
Таулар артына
Күмелгәч кояш.

Доктор Фауст

музыка Наталии Максютиной
перевод с английского Самуила Маршака




Припев:
ре - меш - ком, пал - кой, скал - кой, ку - ла - ком.
до Нью - Йор - ка — хоть ку - да за - го - нит пор - ка. Ой!
Ай! Наш док - тор Фа - уст "доб - рый"
ма - лый. Ой! Ай! Он у - чит
1.
2. Для окончания
де - ток чем по - па - ло. Ой! — па - ло.







Наш доктор Фауст очень “добрый” малый,
Он учит, учит деток чем попало:
И розгой, и плеткой, и ремешком,
Палкой, скалкой, кулаком.

Припев:

Ой! Ай!
Наш доктор Фауст “добрый” малый,
Он учит деток чем попало.

И пляшет, пляшет школа в час урока
Из Великобритании в Марокко,
А из Марокко до Нью-Йорка —
Хоть куда загонит порка.

Припев.

Дождевая песенка

музыка Наталии Максютиной
слова Н.Максютиной и Н.Соколовой

Con moto




2.
Припев
/ —ты.
И по кры-шам, и по стек - лам
ба-ра-ба-нит, ба-ра-ба-нит дождь.
Все на у-ли-
1.
це про - мок-ло, ни-че-го су-хо-го не най - дешь!
2.
/ —дешь! Ля-ля-ля-ля - ля, по-ли-вай силь - ней! Толь-ко под-дож-


дем мы рас- тем быс - трей. "Ля - ля - ля - ля - ля" — ка - пель - ки по -
ют дож - де - ву - ю пе - сен - ку сво - ю. Ля - ля - ля - ля -
ля, по - ли - вай - силь - ней, толь - ко под дож - дем мы рас - тем быс -
трей. "Ля - ля - ля - ля - ля", — ка - пель - ки по - ют дож - де - ву - ю


пе - сен - ку сво - ю.
Дож - дик, на - по - и во - до - ю, дож - дик, на - по - и во - до - ю
Гром - кой пес - ней дож - де - во - ю, гром - кой пес - ней дож - де - во - ю
все цве - ты и тра - ву.
раз - бу - ди все во —
—круг.



Летний дождь из тучи брызнул,
Летний дождь из тучи брызнул на траву и кусты.
И бежим с веселым визгом,
И бежим с веселым визгом под дождем я и ты.

И по крышам, и по стеклам
Барабанит, барабанит дождь.
Все на улице промокло,
Ничего сухого не найдешь.

Ля-ля-ля-ля-ля, поливай сильней!
Только под дождем растем мы быстрей.
"Ля-ля-ля-ля-ля" — капельки поют
Дождевую песенку свою.

Дождик, напои водою, дождик, напои водою
Все цветы и траву.
Громкой песней дождевою, громкой песней дождевою
Разбуди все вокруг.

И по крышам, и по стеклам
Барабанит, барабанит дождь.
Все на улице промокло,
Ничего сухого не найдешь.

Ля-ля-ля-ля-ля, поливай сильней!
Только под дождем растем мы быстрей.
"Ля-ля-ля-ля-ля" — капельки поют
Дождевую песенку свою.

Уточка, прилетай!

музыка Наталии Максютиной
слова Раисы Коротковой




пе - рыш-ка бе - лых ле - жат на ок-не — э - то на па - мять,
э - то на па - мять, э - то на па - мять мне. Я
после 2-го и 3-го куплетов
Ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла,
8
ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла,



Я жду тебя, уточка в красных чулочках,
Веселая уточка, селезня дочка.
Два перышка белых лежат на окне —
Это на память, это на память, это на память мне.

Я знаю, что ты прилетела прощаться,
Я знаю, что ты не смогла достучаться.
Сказать мне: “Прощай, надоели дожди,
Вместе с весною, вместе с весною, вместе с весною жди!”

Метели давно свои песни пропели,
И тают сосульки, сугробы осели.
В окно постучи мне крылом в тишине,
Станет теплее, станет теплее, станет теплее мне!

Red River Valley

английская народная песня

Rubato

обработка Лилии Тагировой




say you are ta - king the sun - shine,
That brigh -
8
tens our path way a while.
Piu mosso
Come and
sit by my side if you love me,
Do not has - ten to
bid me a - dieu.
But re - mem - ber the Red Ri - ver


Val-ley, And the girl that has loved you so
true.
Won't you think of the
Val - ley you're lo - ving? Oh, how


lone - ly, how sad it will be.
Oh, think of the fond heart you - 're
brea - king, And the grief you are
ca - u - sing me?



From this Valley they say you are going,
We will miss your bright eyes and sweet smile.
For they say your are taking the sunshine,
That brightens our path way a while.

Come and sit by my side if you love me,
Do not hasten to bid me adieu.
But remember the Red River Valley,
And the girl that has loved you so true.

Won't you think of the Valley you're loving?
Oh, how lonely, how sad it will be?
Oh, think of the fond heart you're breaking,
And the grief you are causing me?

I have promised you, darling, that never,
While a word from my lips, cause you pain;
And my life it will your's forever,
If you only will love me again.

Осенняя песенка

музыка и слова Лилии Тагировой




Дож - дик ка - па - ет о - пять, мы не смо - жем
по - гу - лять.
Пти - цы в теп - лы - е
кра - я у - ле - те - ли до по - ры,


А мы в лес пой - дем, друзь - я, со - би - рать ско -
рей гри - бы.
Се - рень - ка - я
ко - шеч - ка се - ла у о - ко - шеч - ка.



Вот и осень к нам пришла,
Пожелтела вся листва.
Дождик капает опять,
Мы не сможем погулять.

Птицы в теплые края
Улетели до поры,
А мы в лес пойдем, друзья,
Собирать скорей грибы.

Серенькая кошечка
Села у окошечка.
“Мяу, мяу” — она поет,
Нас с тобою в гости ждет.

Кышкы бишек җыры

Лилия Таһирова музыкасы
Нәҗибә Сафина сүзләре





Тиздән Кыш бабай килә
Ап-ак карлары беләп,
Алып килә уенчык —
Менә шундый зур капчык.
Капчыкта бар куян да.
Йокла, балам, уянма.

Кыш бабайның юлына
Ап-ак карлар коела,
Кар чәчәкләрен чөеп,
Куяннар йөри биеп.
Куяннар ак мамыктай,
Ә минем кызым йоклый.

Әле күктә ай балкый,
Кыш бабай юлдан атлый.
Килер юлы бик озын,
Йокың да туяр, кызым,
Әле алда төн озын,
Әле алда төн озын.

Яз галәмәтләре

Лилия Таһирова музыкасы
Касыйм Тәхау сүзләре

Moderato




боз-лар а-га су-лар шау-лый.
боз-лар а-га, су-лар шау-лый.
Зән-гәр күк-тән ко-яш ал-тын
Зән-гәр күк-тән ко-яш ал-тын
ну-рын си-бә.
ну-рын си-бә.


Дәрт - ле яз - дан без - нең йө - рәк
Дәрт - ле яз - дан без - нең йө - рәк
яр - сып ти - бә. м.. м.. м.. м.. м..
яр - сып ти - бә, яр - сып ти - бә.
м.. м..



Көньякның саф, йомшак җиле
Кышны каулый.
Карлар эри, бозлар ага,
Сулар шаулый.

Зәңгәр күктән кояш алтын
Нурын сибә.
Дәртле яздан безнең йөрәк
Ярсып тибә.

Матур чакта — ямьле язда,
Шаулы язда
Кыйгылдаша кыр казлары
Безнең сазда.

Киек кошлар килде безгә
Җылы яктан.
Алар безгә җәйге кунак
Бик ерактан.

Бишек жыры

Ренат Хәкимов музыкасы
Габдулла Тукай сүзләре




Га - лим бу - лып жи - тәр бу.
Йок - ла, уг - лым, йом кү - зең,
Йом - йом кү - зең, йол - ды - зым;


Кич - тән йо - кың ка - ла - да,
Егъ - лап ү - тә көн - де - зен,
Әл - ли, бәл - ли көй - лә - рем,
Хи - кә - я - ләр сөй - лә - рем,


Си - на бә - хет те - лә - рем,
Бә - хет - ле бул, ди - я - рем.
Ped.
Гыйз - зә - тем син, ка - дрем, син,


Ми - нем йө - рәк бәгъ - рем син,
Ку - а - ны - чым, шат - лы - гым
Тик син ми - нем, син - сең, син!



Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым,
Тик син минем, синсең, син!

Кызыклы шәкерт

Ренат Хәкимов музыкасы
Габдулла Тукай сүзләре

Allegro




—Ник га-зап-лый - сың бо-лай син, мин ә-ле бик кеч - ке-нә;
Мин ту-ган - га тик и-ке ай-лап бу-лыр, йә өч ке-нә.


Юк, ки-рәк - ми, мин өй-рән - мим, ми-нем уй - ный - сым ки-лә;
Шул бо-лын - нар - да я - та - сым, шул-да ау - ный - сым ки-лә.


Ах, ю - ләр ма - э - май! Ты - рып яшь - ләй, зу - рай - гач жай - сыз уң
Кар - та - еп кат - кач бу - ын - нар, эш бе - лү у - ңай - сыз ул!



— Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума, туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә.
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

— Ах, юләр, маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!

Борын-борын заман булган...

Ренат Хәкимов музыкасы
Шәүкәт Галиев сүзләре




f
тым ми-кән? Күз(е)-күз за-ман жи-тү бе-лән ә-н(е)-кәй си-ңа бак-
f
mp
тым ми-кән? Ко-лак-ко-лак за-ман-да мин би-шек жы-рын тың-ла-
mp
f
дым-мы? Ку-л(ы)-ку-л(ы) за-ман ки-леп жит-кәч, кур-чак а-лып уй-на-
f


дым - мы? Кү-л(е) - күл за - ман ки - леп жит-кәч, кур - чак а-лыш уй-на-
дым - мы? А - як-а - як за - ман бул-гач, тә - ни-тә - пи ат-ла-
дым-мы? Те-л(е) - тел за - ман ки - лү бе-лән сөй-лә - шә дә баш-ла -


дым-мы? Бо - рын - бо - рын за - ман - га - ча а - выз - а - выз за -
mf
ман бул-ган. Ә - ни сө - те бе - лән ми-ңа тәм ле - тат-лы сүз-
f
ләр тул-ган. Ә - ни сө - те бе - лән ми-ңа тәм - ле - тат-лы сүз -



Борын-борын заманда
Мин борын сузып яттым микән?
Күз-күз заман житү белән,
Әнкәй, сиңа бактым микән?

Колак-колак заманда
Мин бишек жырын тыңладыммы?
Кул-кул заман килеп житкәч,
Курчак алып уйнадыммы?

Аяк-аяк заман булгач,
Тәпи-тәпи атладыммы?
Тел-тел заман килү белән
Сөйләшә дә башладыммы?

Борын-борын замангача
Авыз-авыз заман булган.
Әни сөте белән миңа
Тәмле-татлы сүзләр тулган.

Чишмә

Фәрит Галиев музыкасы
С. Җиһаншина сүзләре

Animato



Тау астыннан чишмә ага,
Әйтерсең лә моң чыга.
Су алырга кызлар килгән,
Жыр сузалар тын гына.

Гүзәл чишмә — иң саф чишмә,
Ни дип челтери икән?
Кызларга моң көйли микән,
Әллә сер сөйли микән?

Су эчә кызлар чишмәдән,
Моңга күмелә күңел.
Шифасы күп чишмәкәйнен,
Жырламый мөмкин түгел.

Бөркет

Фәрит Галиев музыкасы
С. Җиһаншина сүзләре

Tempo di Marcia



Батыр, кыю егетләрне
Бөркетләргә тиңлиләр.
Безне көтә бик зур эшләр,
Алда безнең җиңүләр.

Кушымта:

Без – егетләр, егетләр,
Бар да бөркет кебекләр.
Үрләргә менәрбез без,
Галәмгә җитәрбез без.
Без – егетләр, егетләр.

Җырларыбызны ишетсен
Моңлы урман, киң алан.
Сакта тора бөркетләрең,
Тыныч бул син, Җир - анам!

Кушымта.

Бер саф булып, тезелешеп,
Бастык сезнең каршыга.
Егетләр – бөркет кебекләр,
Менә диган барсы да.

Кушымта.

Ләйсән җыры

Фәрит Галиев музыкасы
Нур Әхмәдиев сүзләре

Allegretto



Явып узсын ләйсән яңгыр,
Курыкма, әйдә, чылан.
Без бүгенге җырыбызны
Отып алдык тамчыдан.

Кушымта:
Дин-дин, мин — ләйсән,
Дин-дин, без — ләйсән!
Сусаган күңелгә без,
Ләйсән яңгырлар шикелле,
Җыр булып түгеләбез.

Ләйсән яңгырлардан откан
Җырны алып юлдашка,
Әйдәгез, дуслар, бергәләп
Юл салабыз кояшка.

Кушымта.

Көлә кояш, ява яңгыр,
Туктар микән ул бүген?
Ләйсән яңгырлары юа
Бакчада гөл керфеген.

Кушымта.

Хыялларга канат куеп
Яши торган чорда без.
Күңеллерәк булыр бергә,
Дуслар, сез дә җырлагыз!

Кушымта.

ЭЧТӘЛЕК - СОДЕРЖАНИЕ

Сүз башы 3
Предисловие 4
БЕЗ — ДӨНЬЯ БАЛАЛАРЫ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Роберт Миңнуллин сүзләре* 5
ӘЛЛИ-БӘЛЛИ БӘҮ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Басыйр Рафиков сүзләре* 7
ЭНЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Азат Садриев сүзләре* 9
МИНЕМ ҖЫРЛЫЙСЫМ КИЛӘ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Лена Шагыйрьҗан сүзләре* 11
БАЛАЛАР ТАВЫШЫ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Хәй Вахит сүзләре* 12
СИН КАЙГЫРМА, ӘНКӘЙ! *Гөлназ Зарипова музыкасы, Гөлзада Әхтәмова сүзләре* 13
КОЙРЫК. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Гөлзада Әхтәмова сүзләре* 14
КАР КЫЗЫ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Гөлназ Гарипова сүзләре* 15
ИНЕШ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Клара Булатова сүзләре* 16
УЙНА, ДУСКАЙ, ГАРМУНЫҢНЫ. *Гөлназ Зарипова музыкасы, Шәриф Биккол сүзләре* 17
ӨЕБЕЗНЕҢ КОЯШЫ. *Эльмира Гыйльфанова музыкасы, Фирая Зыятдинова сүзләре* 18
БАЛАЧАГЫМ. *Эльмира Гыйльфанова музыкасы, Энҗе Афзалова сүзләре* 19
ТУРГАЙ. *Эльмира Гыйльфанова музыкасы, Айрат Мурзыев сүзләре* 20
КАР БӨРТЕКЛӘРЕ. *Эльмира Гыйльфанова музыкасы, Мизхәт Хәбибуллин сүзләре* 21
ДОКТОР ФАУСТ. *Музыка Наталии Максютиной, перевод с английского Самуила Маршака* 22
ДОЖДЕВАЯ ПЕСЕНКА. *Музыка Наталии Максютиной, слова Н.Максютиной и Н.Соколовой* 25
УТОЧКА, ПРИЛЕТАЙ! *Музыка Наталии Максютиной, слова Раисы Коротковой* 30
RED RIVER VALLEY. *Английская народная песня, обработка Лилии Тагировой* 33
ОСЕННЯЯ ПЕСЕНКА. *Музыка и слова Лилии Тагировой* 38
КЫШКЫ БИШЕК ҖЫРЫ. *Лилия Таһирова музыкасы, Нәҗибә Сафина сүзләре* 42
ЯЗ ГАЛӘМӘТЛӘРЕ. *Лилия Таһирова музыкасы, Касыйм Тәхау сүзләре* 44
БИШЕК ҖЫРЫ. *Ренат Хәкимов музыкасы, Габдулла Тукай сүзләре* 48
КЫЗЫКЛЫ ШӘКЕРТ. *Ренат Хәкимов музыкасы, Габдулла Тукай сүзләре* 54
БОРЫН-БОРЫН ЗАМАН БУЛГАН... *Ренат Хәкимов музыкасы, Шәукәт Галиев сүзләре* 59
ЧИШМӘ. *Фәрит Галиев музыкасы, С. Җиһаншина сүзләре* 64
БӨРКЕТ. *Фәрит Галиев музыкасы, С. Җиһаншина сүзләре* 65
ЛӘЙСӘН ҖЫРЫ. *Фәрит Галиев музыкасы, Нур Әхмәдиев сүзләре* 66

Мы - дети мира

(на татарском и русском языках)

Литературный редактор А.Юнысова
Художественное оформление Ш.Насыров
Компьютерная верстка В.Порсев
Компьютерный набор нот и текста С.Багавиев
Корректор Ф.Алтынбаева

Формат 60x90/8. Бумага офсетная. Гарнитура Таймс.
Печать офсетная. Усл.печ.л. 8,5. Тираж 2000 экз. Зак

Налоговая льгота - общероссийский классификатор продукции
ОК-005-93; т.2; 95300 - книги, брошюры.

Отпечатано в типографии
Управления Делами Президента Республики Татарстан.

ФАТИХА

Кадерле музыка сөюче дустым! Бәхетле халыкларның бәйрәмнәре күп була, диләр. Синең кулыңдагы көйләр җыентыгы шул гыйбарәнең бер чагылышы. Әлбәттә, бу көйләр тупланмасында иҗатчыларның һәрбер җыры энҗе бөртеге түгел. Әмма аларның туган илне, туган җирне данлаган җырлары ихтирамга лаек. Әгәр дә бу илһам ияләре вакытында профессиональ белем алып, композиторлык юлын сайласалар, иманым камил, Әлмәт төбәге һәм Татарстан гына түгел, бәлки дөнья горурланырлык шәхесләр пәйда булыр иде. Музыка сөюче дустым, син игътибар белән бу иҗат җимешләрен барлап чыксаң, һичшиксез, үзеңә ошаган көйләр сайлый алырсың. Хикмәт җырның язылуында гына түгел бит, аның башкарылуында да. Башкарылган җырлар исә бәхетле халыкның бер балкышы.

Мәсгудә Шәмсетдинова,
композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

НАПУТСТВИЕ

Дорогой друг! То, что ты взял в руки эту книгу, говорит о твоей любви к музыке. И это неудивительно. Ведь именно в музыке раскрывается душа человека, только в ней изливает он всю свою печаль и радость. Наверное, по песням можно проследить историю народа, понять его беды и чаяния. Произведения, вошедшие в этот сборник — также отражение своего времени. Возможно, они не вполне совершенны, ведь их авторы только вступили на путь профессионального творчества. Главное то, что они искренни в своих чувствах к родному краю, к воспеваемой отчизне. Кто знает, если бы эти таланты в свое время получили академические знания, может они бы прославили не только свой Альметьевский край, и не только нашу республику, возможно ими гордился бы мир. А пока, дорогой друг, оцени эти творения, не судя строго, и выбери песню, созвучную песне твоей души. Может быть, именно ты станешь ювелиром, своим исполнением превратившим алмаз в бесценный бриллиант.

Масгуда Шамсутдинова,
композитор, заслуженный деятель искусств Республики Татарстан.